**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**“АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЯСЕ**

| **«КАРАЛДЫ»** | **«КИЛЕШЕНДЕ»** | **«РАСЛАНДЫ»** |
|---|---|---|
| Методик берләшмә житәкчесе<br>__________Замалиева И.Х.<br>МБ утырышы беркетмәсе<br>№1 25 август 2016 ел | Директор урынбасары<br>_______Л.Р.Ягудина<br><br>27 август 2016 ел | Мәктәп директоры<br>_______Л.Н.Липлянина<br>Педагогик совет беркетмәсе<br>___ нче номерлы боерык белән гамәлгә кертелде.<br>31 август 2016 ел |

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Чибинова Лилия Рәис кызы
8 «б» сыйныфы өчен әдәбияттан
эш программасы

Педагогик киңәшмә
Утырышында каралды.
Беркетмә №1
31 август 2016 ел

**2016 - 2017**

## **1.Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.**

Сыйныф: *8“Б”*
Укытучы: *Чибинова Л.Р*
Уку планы буенча
Татар әдәбиятыннан: *70 сәг.*
Атнага: *2 сәг.*
Тест:3
Проект эше:2
Административ контроль эш:1
Дәреслекләр. Мотыгуллина Ә.Р., Ханнанов Р.Г., Гыйзәтуллина Э.Х., Татар әдәбияты, 8 класс. Казан “Мәгариф - Вакыт” нәшрияты 2014 ел.
Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:
1.Программа: Татарстан РеспубликасыМәгарифһәмфәнминистрлыгы. Урта (тулы) гомумибелембирүмәктәбендәрустеллебалаларга татар теленкоммуникатив технология нигезендәукытупрограммасы (1 — 11 нчесыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.
2.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомумибелемучреждениясе “Аерымпредметларнытирәнтенөйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белембирү баскычында төп гомуми белем бирү программасы.
3.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомумибелемучреждениясе “Аерымпредметларнытирәнтенөйрәнүче Алексеевск 2 нчеуртагомумибелеммәктәбе”нең 2016-2017укуелынаукытупланы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2016 ел).
Эш программасы татар әдәбиятын, әдәби, фәнни, публицистик стильләрдә язылган текстларны укып, андагы сөйләм үрнәкләре нигезендә төрле ситуацияләр буенча телдән аралаша белергә өйрәтүне, әсәрләргә, андагы образларга кыскача характеристика бирә белергә өйрәтүне күз алдында тота. Моңа укыту планы нигезендә атнага 2 дәрес каралган, барлыгы 70 дәрес.
8 нче сыйныфта укучы рус телле балаларга татар әдәбиятын дәүләт теле буларак укыту түбәндәге максат һәм бурычларны күзаллый:
-рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле буенча системалы белем бирү.
-аларны ирекле аралашырга өйрәтү.
-татар дөньясы турында күпкырлы мәгълүмат бирү.
-татар сөйләмен тыңлап аңларга күнектерү.
-бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештырырга өйрәтү.
-программада күрсәтелгән лексик темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү.
-төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен үстерү.
-тәкъдим ителгән текстларны яттан өйрәнү.
-фразеологик берәмлекләрнең, мәкальләрнең рус эквивалентларын табарга һәм чагыштырырга өйрәтү.
-татар сөйләмен фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү.
-күренекле шәхесләр белән таныштыруны дәвам итү.

-халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенә омтылыш тәрбияләү.

Тыңлап аңлау

Өч минутлык текстны тыңлап, аның эчтәлеге буенча сөйләшү (полилог) үткәрү;
диктор сөйләмен тыңлап, эчтәлеге буенча мөстәкыйль эшләр эшләү.

Диалогик сөйләм

Укылган (тыңланган) текстның эчтәлеге буенча фикер алышуда катнашу;
кара-каршы сөйләшү барышында аралашу максатына ирешү һәм үз фикереңне белдерү;
тәкъдим ителгән ситуация буенча сөйләшү үткәрү (һәр укучының репликалар саны 10 нан ким булмаска тиеш)

Монологик сөйләм

Табигать күренешләрен, төрле вакыйгаларны тасвирлау;
иҗтимагый һәм мәдәни тормыш яңалыклары турында хәбәр итү (җөмләләр саны 12 дән ким булмаска тиеш);
укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген эзлекле итеп сөйләп бирү.

Язу

Өйрәнелгән темалар буенча актив кулланууда булган сүзләрне дөрес яза белү;
конкрет бер тема буенча хикәя төзи белү;
прагматик текстлар (рецептлар, белдерүләр, афиша һ.б.), эпистоляр жанр текстлары (хатлар, котлаулар һ.б.) яза белү;
тәкъдим ителгән текстның эчтәлегенә нигезләнеп, аны үзгәртеп яки дәвам итеп яза белү;

Уку

Әдәби әсәрләрдән алынган өзекләрнең, фәнни-популяр текстларның эчтәлеген тулысынча аңлап уку, кирәкле
мәгълүматны табып әйтү;
шигырьләрне яттан өйрәнү һәм сәнгатьле итеп сөйләү.

## II. Укыту предметының эчтәлеге

**I.** Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана

Халык авыз иҗаты. Фольклор жанрлары буларак риваятьләр, аның ничек барлыкка килүе. Риваять төрләре.

Тарихи риваятьләр.*Татар халыкының“Сихерче кыз” риваяте.* Әсәрдә Казан образының бирелеше, тарихы. Әлеге риваятькә хас әкияти алымнар *(1 сәгать).*

*Топонимик риваятьләр.* Татар халкының “Гали тугае” риваяте.Урта гасыр Европа халкының “Моргана”риваяте. *Шәһәр, авыл, тау һәм елга атамаларының килеп чыгышы (2 сәгать).*

*Легендалар. Аның төрләре. Легенданың риваятьтән аермалы яклары.*

Татар халкының «Зөһрә кыз» легендасы. Легендада Зөһрә образының бирелеше. Әсәрдә хыял мотивлары, аның кеше язмышын ачудагы роле. Әсәрдә гаиләдәге мөнәсәбәтләрнең бирелеше *(1 сәгать).*

Музыка уен кораллары, аларның халык тормышындагы роле *(1 сәгать).*

**II.** Без тарихта эзлебез

Тарихи ядкарьләр буларак сәяхәтнамә һәм елъязма жанрлары.Ибне Фадлан – X гасырның беренче яртысында яшәгән гарәп сәяхәтчесе. Ибн Фадланның 921 – 922 нче

елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсе. Болгар дәүләтенең ил тарихындагы роле. Ил башлыгы Алмыш хан *(1 сәгать).*

Фатих Кәрими. Әдип һәм журналист тормышы һәм иҗат юлы. Аның Европа илләренә сәяхәте, бу сәяхәтнең максаты.«Аурупа сәяхәтнамәсе» әсәреннән өзек. Европа илләрендәге культура учаклары, Петербург китапханәсе турында мәгълүмат. «Аурупа сәяхәтнамәсе»нең әдәби роле*(1 сәгать).*

Миргазиян Юныс. Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә.Татар әдәбиятында диңгезчелек (маринистика) жанрына нигез салуы. Язучының “Су” хикәясе *(1 сәгать).*

*Әдәбият теориясе. Тарихи роман турында төшенчә (1 сәгать).*

Тарихи һәйкәл буларак Казан Кремле, аның төзелү тарихы. Кремльнең бүгенге торышы.

Габдулла Тукай.Язучының 1895 нче елда Җаек (Уральск) шәһәренә китүе. Анда Тукайның җәмәгать эшлеклесе, журналист, тәрҗемәче һәм шагыйрь буларак формалашуы.1907 нче елда кире Казанга кайтуы. Шагыйрь иҗатының Казан чоры. Казанда аралашкан дуслары, балалар әдәбиятына һәм халык әдәбиятын өйрәнүгә керткән өлеше, театр эшчәнлегенә игътибары, сәяхәтләре, иҗтимагый эшчәнлеге. “Әл-ислах” газетасындагы эшчәнлеге. Габдулла Тукайның “Пар ат” шигыре. Аның язылу тарихы. “Пар ат” шигыренең лирик герое, аның кичерешләре, өметләре. Пар ат образының символикасы. Табигать, кучер образларының бирелеше, мәгънәләре *(2 сәгать).*

Бакый Урманченың “Пар ат” шигыренә иллюстрациясе. Картинада Габдулла Тукай шигырендә сурәтләнгән вакыйганың бирелеше.

Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе. Премиянең беренче лауреатлары.

Күренекле рәссам, сынчы Бакый Урманченың (1897 – 1990) тормышы. Ул тудырган скульптур портретлар, картиналар *(1 сәгать).*

Нажар Нәҗми.Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы. Аның Тукай шәкерте булуы, аның идеяләрен үстерүе. Н.Нәҗми иҗат иткән әсәрләрдә Тукай образының бирелеше, мәгънәсе. Шагыйрьнең «Татар теле» әсәрендә Тукай традицияләрен дәвам итүе. Н.Нәҗминең Бөек Болгарга сәфәре турындагы “Агыйделдә ак пароход” әсәреннән өзек. Әсәрдә сурәтләнгән “түгәрәк өстәл”, анда катнашкан язучылар. Әсәрнең әдәби мәгънәсе, кыйммәте *(1 сәгать).*

**III.** Онытылмас еллар

Гариф Ахунов. “Замандашлар портреты” әсәреннән өзек. Язучының әсәрдә рәссам Виктор Куделькинның иҗатын яктыртуы, аның картиналары турында уйланулары. Рәссам иҗатында М.Җәлил образы, аның бирелеше, иҗатчының халык язмышының кискен дәверләрен полотнода сурәтләве. В.Куделькинның “Билгесез биеклектә” картинасы, Бөек Ватан сугышы *(1 сәгать).*

Сугыш турындагы җырлар. Роберт Әхмәтҗановның “Озатып вокзаллар каршында…” (“Солдатлар”) шигыре. Сугышка баласын озаткан Ана образы. Татар халкының “Герман көе” җыры. Музыка сәнгатенең матур әдәбият белән тыгыз бәйләнештә булуы һәм бер-берсенә йогынтысы *(1 сәгать).*

Фатих Кәримнең тормышы, иҗаты. Аның иҗатында сугыш темасы, образларның бирелеше. Шагыйрьнең “Ант” шигыре, «азатлык» һәм «явызлык» проблемалары. “Кыңгыраулы яшел гармун” поэмасы, андагы образлар системасы. Гармун һәм җыр образының роле. Әлеге лирик әсәрләрдә сугыш проблемасының бирелеше *(3 сәгать).*

Туфан Миңнуллин. Күренекле драматург, язучы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесенең тормышы һәм иҗаты. “Моңлы бер җыр” драмасы. Әсәрдә М.Җәлил образының бирелеше, аның тоткынлыктагы тормышы. Драмада фәлсәфи мотивлар, фантастик алымнарның роле. Т.Миңнуллинның “Моңлы бер җыр” публицистик драмасы турында белешмә*(2 сәгать).*

Казанда Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләргә куелган барельефлар.

Марсель Сәлимҗанов. Режиссёрның тормышы, иҗаты. Аның татар профессиональ театрының, милли драматургиянең үсешенә керткән өлеше.

Ринат Тажетдинов. Халык артистының тормышы һәм иҗаты, ул тудырган онытылмас образлар*(1 сәгать).*

Фронт хатлары, аның халык тормышындагы роле. Муса Җәлилнең кызы Чулпанга язган хаты, Фәтих Кәрим хатлары.Татарәдәбиятында эпистоляр жанр.

*Әдәбият теориясе. Эпистоляр жанр турында төшенчә (1 сәгать).*

Мостай Кәрим. Шагыйрь һәм язучының тормышы, иҗаты. “Билгесез солдат” шигыре. Шигырьдә билгесез солдат образы.Лирик геройның кичереше, шәхесләр язмышы *(1 сәгать).*

Чыңгыз Айтматов. Әдип турында белешмә. Аның “Анам кыры” әсәре. Әсәрдә Тулганай, Җир-ана образлары. Җыелма Җир-ана образына салынган мәгънә. Авторның сугыш турындагы уйланулары. «Анам кыры» повесте турында белешмә*(1 сәгать).*

Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау *(1 сәгать).*

**IV.** Әтинең зур бүреге иртә киелде

Клара Булатова. Шагыйрә турында белешмә. “Башым иям” шигыре, сугыш афәтенең шагыйрәнең балачагына тәэсире, хатирәләрендә калдырган эзе *(1 сәгать).*

Нур Әхмәдиев. Язучы иҗаты турында белешмә.“Җиңү көне” шигыре. “Минем туган көнем” хикәясе*(2 сәгать).*

Факил Сафин. Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Тулганай” әсәреннән өзекләр. Тулганай образы, аның әсәрдәге башка образларны ачудагы әһәмияте. Әсәрдә кешелеклек, шәфкатьлелек проблемалары *(2 сәгать).*

Разил Вәлиев. Тормышы һәм иҗади эшчәнлеге. “Ватаным” шигыре. Сугыш, аның гади халык, балалар җилкәсенә алып килгән авырлыгы *(1 сәгать).*

Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау *(1 сәгать).*

**V.** Ана — изге, Ана — бөек, аңа — дан!

Аңлар өчен йөрәгенең олылыгын,

Туу кирәк кайчак безгә яңадан!

Шәриф Камал. Әдипнең тормышы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. “Буранда” новелласы. Төп геройның язмышы. Аның эчке дөньясы, күңел халәте. Психологик алымнар. Әсәрдә Ана образына хас сыйфатлар.

*Әдәбият теориясе. Әдәби деталь. Матур әдәбиятта психологизм. Новелла турында төшенчә (2 сәгать).*

Ибраһим Салахов. Язучының тормышы һәм иҗаты. Репрессияләнгән әдипләр язмышы. “Халык дошманы” төшенчәсе. “Ана тавышы” хикәясе (“Колыма хикәяләре” циклыннан).Ялгыз ананың аяныч язмышы, кичерешләре. Автор әйтергә теләгән фикер *(2 сәгать).*

Сибгат Хәким. Шагыйрьнеңтормыш юлы, иҗаты турындамәгълүмат. Иҗатында яктырткан темалар. “Әнкәй” шигырендәАна образына хас сыйфатлар. Лирик геройның хис-кичерешләр бирелеше. Сагыну хисе. “Җырларымда телим” шигыре. Шигырьнең эчтәлеге, поэтик яңгырашы, сурәтләү чаралары. Шигырьдә күтәрелгән проблемалар *(2 сәгать).*

Роберт Миңнуллин. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты. Әдәбиятка булган мәхәббәте. Иҗатында яктыртылган темалар. “Әнкәй” шигыре. Ана образының бирелеше. Лирик геройның уйлары, кичерешләре *(1 сәгать).*

Марсель Галиев. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат. “Су буеннан әнкәй кайтып килә” шигыре. Шигырьдә ана образы. Лирик геройның туган ягы турында хис-кичерешләре. “Кабатланмас әкият” шигыре. Хыялда туган авыл күренеше. Балачакка кайту теләге, лирик геройның хис-кичерешләре. Ана образының бирелеше Луиза Батыр-Болгари. Композиторның тормыш юлы, иҗаты *(2 сәгать).*

Шәриф Хөсәенов. Әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат. Беренче драмалары турында белешмә. “Әниемнең ак күлмәге” (“Әни килде”) драмасы. Драмада ана образының бирелеше. Ананың язмышы, балаларына булган мәхәббәте. Автор әйтергә теләгән фикер. Шәриф Хөсәеновның “Әниемнең ак күлмәге” (“Әни килде”) драмасы турында.Драманың татар әдәбиятында тоткан урыны. Ана образы турында мәгълүмат. Аналар һәм балалар проблемасы *(2 сәгать).*

Фоат Садриев. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Таң җиле” романы.Романда бирелгән образларның язмышы, ана (Нуриәсма) образының бирелеше. Нәсимә белән Фәритнең үз-үзләрен тотышы, уллары Маратның авылда терелүе, сөйләшә башлавы, дуслар табуы. Авторның әйтергә теләгән фикере *(3 сәгать).*

Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау *(1 сәгать).*

VI. Көлсәң – көл, еласаң – ела!

Беренче сатирик журналлар. Беренче сатирик журналлар турында белешмә. Вакытлы матбугатны башлап җибәргән шәхесләр.

*Әдәбият теориясе. Сатира турында төшенчә(1сәгать).*

Галиәсгар Камал. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты, татар әдәбиятында тоткан урыны. “Банкрот” сатирик комедиясе. Сираҗетдин Туктагаевның тормыш, көнкүреше, уйлаган хәйләсе. Тирә-юньдәге образларның үз-үзләрен тотышы. Галиәсгар Камалның “Банкрот” комедиясе турында белешмә. Әсәрнең сәхнә тарихы. Әдип тарафыннан күтәрелгән проблема.

*Әдәбият теориясе. Конфликт турында төшенчә. Сарказм. Проза әсәрләрендә сатира (2 сәгать).*

Гамил Афзал. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат.Юмор-сатира өлкәсендә тоткан урыны“Юл газабы” хикәясе.Хикәяләүче авторның язмышы турында белешмә. “Тәвәккәл әби” шигыре.Әбинең аянычлы язмышы, эш-гамәлләре. Шигырьнең эчтәлеге, поэтик яңгырашы. Автор идеясе. Сурәтләү чаралары. Шигырьдә күтәрелгән проблемалар.

*Әдәбият теориясе. Сатирик шигырь. Ирония турында төшенчә (2 сәгать).*

Зәки Нури. “Пародия”. Пародиянең язылу стиле. Пародиягә салынган эчтәлек. Төрле шәхесләргә багышланган эпиграммалар. Эпиграммаларда сарказм.

*Әдәбият теориясе. Пародия турында төшенчә.Эпиграмма (1сәгать).*

Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау *(1 сәгать).*

VII.Даhи гомере – халкы хәтерендә!

Ренат Харис. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Гармунчы” поэмасы. Поэманың эчтәлеге. Лирик геройның бирелеше. Поэмада кулланылган сурәтләү чаралары. Гармуннан чыккан көйләрнең сурәтләнеше. “Ике гөл” шигыре.Шигырьнең идеясе, төзелеше. Шигырьгә салынган мәгънә. Автор әйтергә теләгән фикер *(2 сәгать).*

Зөлфәт. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Юмор-сатира өлкәсендә ирешкән уңышлары. “Шигырем – ачык!” ,“Шундый чагы әле җанымның” шигырьләре.Аларда лирик геройның хис-кичерешләре. Әдип шигыренә хас үзенчәлекләр.

*Әдәбият теориясе. Документаль повесть жанры (2 сәгать).*

Галия Кайбицкая. Актрисаның тормыш юлы турында белешмә. Татар музыка сәнгатен һәм операсын үстерүгә керткән өлеше *(1 сәгать).*

Рабит Батулла. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Төрле жанрларда иҗат итүе. “Бию” кыйссасы.Рудик белән бәйле, госпитальдә булган көлкеле вакыйганың әдәби гәүдәләнеше. Яшь талантның беренче уңышы *(2 сәгать).*

Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау *(1 сәгать).*

VIII. Табигатьнең дә җаны бар.

Айдар Хәлим. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә.“Өч аяклы ат” повесте.Әсәрнең эчтәлеге. Кәбирнең язмышы, атка мөнәсәбәте. Аның тирәсендә булган башка геройларның үз-үзләрен тотышы. Ат образының бирелеше *(3 сәгать).*

Гарәфи Хәсәнов. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Беренче күк күкрәү” хикәясе.Язгы табигать күренешенең сурәтләнеше. Геройның язгы табигать турында уйлары, хис-кичерешләре. Беренче күк күкрәү мизгелләренең тасвирланышы *(2 сәгать).*

Камил Кәримов. Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Тимергали бабай хикәяте” хикәясе. Хикәянең эчтәлеге. Авторның Сабантуй бәйрәмен тасвирлау үзенчәлеге. Заманга хас булган атрибутларның бирелеше (кулъяулык бирү, аулак өй күренеше һ.б.)*(1 сәгать).*

“Ялкын” журналы.Журналның тарихы. Журнал рубрикалары. Мәкаләләрнең эчтәлеге *(1 сәгать).*

Ел дәвамында үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау *(1 сәгать).*

## III.Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру

| Дә-<br>рес<br>№ | Дәрес темасы | Төп эчтәлек | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Ачыла тарихның пәрдәсе. | Халык авыз иҗаты, риваять жанрына гомуми күзаллау булдыру. “Сихерче кыз” риваятен уку. | 2.09 |
| 2 | Сезгә ялган, миңа чын. | “Гали тугае”, “Моргана” риваятьләрен уку. | 7.09 |
| 3 | Халыкныкы халыкта саклана. | Укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Риваять темасын гомумиләш-тереп кабат-<br>лау. | 9.09 |
| 4 | Сезгә ялган, миңа чын. | Легенда жанрына гомуми күзаллау булдыру. | 14.09 |
| 5 | Моңы барның йөрәгеннән Һәрвакыт җылы чыгар. | Милли уен кораллары белән танышу. | 16.09 |
| 6 | Тарих – тормыш остазы. | Ибн Фадлан һәм аның 921 – 922 нче елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсе белән танышу. | 21.09 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | Гыйлемсез кеше – канатсыз кош. | Фатих Кәрими иҗаты. “Аурупа сәяхәтнамәсе” белән танышу. | 23.09 |
| 8 | Энҗе табучы әдип. | Миргазиян Юныс иҗаты, “Су”хикәясен уку. | 28.09 |
| 9 | Җиктереп пар ат, Казанга. | Габдулла Тукай иҗаты. “Пар ат” шигырен өйрәнү | 30.09 |
| 10 | Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур. | “Пар ат” шигыренә анализ. | 5.10 |
| 11 | Милли мәдәниятебезне үстерүдә Бакый Урманче иҗаты. | Бакый Урманче иҗаты белән танышу. | 7.10 |
| 12 | Нажар Нәҗми - Тукай шәкерте. | Нажар Нәҗминең иҗаты, “Агыйделдә ак пароход” әсәре. | 12.10 |
| 13 | Үзенең үткәнен онытkан халыкның киләчәге юк. | Укылган әсәрләрне, теоретик төшенчәләрне кабатлау. | 14.10 |
| 14 | Билгесез биеклектә. | Рәссам Виктор Куделькинның иҗаты. Гариф Ахуновның “Замандашлар портреты”н уку. | 19.10 |
| 15 | Тырышса да дошман, шагыйрьләрне аералмый җырдан, халыктан. | Роберт Әхмәтҗановның “Озатып вокзаллар каршында” һәм татар халык җыры “Герман көе” белән танышу. | 21.10 |
| 16 | Патриот-шагыйрь. | Фатих Кәрим иҗаты.“Ант” шигырен өйрәнү. | 26.10 |
| 17. | Үлем турында уйлама, илең турында уйла. | Фатих Кәримнең “Кыңгыраулы яшел | 28.10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | гарун” поэмасын уку. | |
| 18. | Үлем турында уйлама,илең турында уйла. | Фатих Кәримнең “Кыңгыраулы яшел гарун” поэмасын уку. | 9.11 |
| 19. | Исемең калды моңлы бер җыр булып | Муса Җәлил иҗаты. | 11.11 |
| 20. | Исемеңкалдымоңлыбер җырбулып... | Туфан Миңнуллин иҗаты.“Моңлы бер җыр” драмасы. | 16.11 |
| 21 | Һәйкәлләргәкилик, гөлләркуйыйк, Һәйкәлләрнетыңлыйктынгына. | Казанда Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләргә куелган барельефлар. | 18.11 |
| 22 | Каз канаты каурый-каурый, Хатлар язарга ярый. | Хатүрнәкләребеләнтанышу, БөекВатансугышыбатырларыныңфронтхатларынуку. | 23.11 |
| 23 | Син күрсәткән батырлыкны, солдат, Халкым сөйли мактап бүген дә. | Мостай Кәрим иҗаты. “Билгесез солдат” шигыре. | 25.11 |
| 24 | Дөньяда тик бары яхшылык кына үлми. | Чыңгыз Айтматов иҗаты. “Анам кыры” әсәре. | 30.11 |
| 25 | Без азатлык алып биргән көннәр, Хәтерләми икән кем генә! | “Онытылмас еллар” бүлегендә өйрәнгән материалларны кабатлау. | 2.12 |
| 26 | Җиңүне якынайткан җыр. | Клара Булатова иҗаты. «Башым иям» шигыре белән танышу. | 7.12 |
| 27-28 | Тынычыкның туган көнен Бәйрәм итә бүген илем... | Нур Әхмәдиев иҗаты. «Җиңү көне» шигыре, “Минем туган көнем” хикәясе. | 9.12 14.12 |
| 29-30 | Шәфкатьлелек бизи кешене! | Факил Сафинның иҗаты.“Тулганай” әсәре. | 16.12 21.12 |
| 31 | Таң булып нур сибә Ватаным. | Рәзил Вәлиев иҗаты.«Ватаным» шигыре. | 23.12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 32 | Җиңү көне җиңел бирелмәде. | “Вакыт сынавы аша...” – проектларны яклау. | 11.01 |
| 33 | Бәхет эзләгәндә. | Шәриф Камал иҗаты.“Буранда” хикәясен уку. | 13.01 |
| 34 | Исән чакта белү кирәк икән,<br>Әти-әниләрнең кадерен. | Шәриф Камалның “Буранда” хикәясен өйрәнү. | 18.01 |
| 35 | Тайгак кичүләрне кичкән шагыйрь. | Ибраһим Салахов иҗаты.<br>«Колыма хикәяләре» циклыннан “Ана тавышы” | 20.01 |
| 36 | Тетрәндергеч еллар авазы. | Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре» циклыннан<br>“Ана тавышы”. | 25.01 |
| 37 | Ана күңеле – балада. | Сибгат Хәким иҗаты, “Әнкәй” шигыре. | 27.01 |
| 38 | Җырларымда телим. | Сибгат Хәкимнең “Җырларымда телим” шигыре. | 1.02 |
| 39 | Әнкәйләрдән күргән игелек. | Роберт Миңнуллин иҗаты, “Әнкәй” шигыре. | 3.02 |
| 40 | Туган җирләр әнкәй белән. | Марсель Галиев иҗаты.“Су буеннан әнкәй кайтып килә шигыре”. | 8.02 |
| 41 | Кабатланмас әкият. | Марсель Галиевның “Кабатланмас әкият” шигыре. | 10.02 |
| 42. | Ата-анага бурычны бары тик кеше булып кына түләп була. | Шәриф Хөсәенов иҗаты, “Әни килде” (“Әниемнең ак күлмәге”) драмасыннан өзек уку. | 15.02 |
| 43. | Ата-анага бурычны бары тик кеше булып кына түләп була. | Шәриф Хөсәенов иҗаты, “Әни килде” (“Әниемнең ак күлмәге”) драмасыннан өзек уку. | 17.02 |
| 44. | Ана куллары. | Фоат Садриев иҗаты. “Таң җиле”әсәре. | 22.02 |
| 45. | Ана куллары. | Фоат Садриев иҗаты. | 24.02 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Таң җиле”әсәре. | |
| 46. | Ана куллары. | Фоат Садриев иҗаты. “Таң җиле”әсәре. | 1.03 |
| 47 | Кая барсам – әнкәй күңелдә. | «Ана – бөек исем! Нәрсә җитә ана булуга...» бүлеген гомумиләштереп кабатлау, бәйләнешле сөйләм үстерү. | 8.03 |
| 48 | Күңелсездән көлке чыкмас. | Сатирик журналлар, Галиәсгар Камал иҗаты. | 10.03 |
| 49. | Хәйләсез дөнья файдасыз. | Галиәсгар Камалның “Банкрот” комедиясе. | 15.03 |
| 50. | Хәйләсез дөнья файдасыз. | Галиәсгар Камалның “Банкрот” комедиясе. | 17.03 |
| 51 | Һәр заманның үз герое була. | Гамил Афзал иҗаты. “Юл газабы” хикәясе. | 29.03 |
| 52 | Сүз күңелдә очкын булып көйри. | Гамил Афзалның “Тәвәккәл әби” шигыре. | 30.03 |
| 53 | Озын сүзнең кыскасы. | Зәки Нури иҗаты, пародия, эпиграммалар | 5.04 |
| 54. | Көлке дисәң дә көлке! | “Көлсәң — көл, еласаң — ела” бүлеген гомумиләштереп кабатлау. | 7.04 |
| 55 | Көйләрдән тезмәләр тездем. | Ренат Харис иҗаты.“Гармунчы” поэмасы. | 12.04 |
| 56 | Минем тирәмдә Кояш үзе әйләнә. | Ренат Харисның “Ике гөл” шигыре. | 14.04 |
| 57 | Шигырем – ачык! | Зөлфәт иҗаты. “Шигырем-ачык”шигыре. | 19.04 |
| 58 | Ерактагы моңлы бер көй булып. | Зөлфәтнең “Шундый чагы әле җанымның” шигыре. | 21.04 |
| 59 | Ил җыр белән яши. | Галия Кайбицкая иҗаты. | 26.04 |
| 60. | Сәхнә хуҗасы. | Рабит Батулла иҗаты. «Бию» хикәясе. | 28.04 |
| 61. | Сәхнә хуҗасы. | Рабит Батулла “Бию”хикәясе. | 3.05 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 62. | Иҗат – ул яшәү рәвеше. | Иҗат процессы бүлеген гомумиләштереп кабатлау. | 5.05 |
| 63. | Батыр Җайдак. | Айдар Хәлим иҗаты.“Өч аяклы ат” повесте. | 10.05 |
| 64. | Фронттан кайткан ат. | Айдар Хәлимнең “Өч аяклы ат” повесте. | 12.05 |
| 65. | Авырлык җебе өзелде. | Айдар Хәлимнең “Өч аяклы ат” повесте. | 17.05 |
| 66. Галиәсгар Камалның “Банкрот” комедиясе. | Табигатьнең чәчәк аткан чагы. | Гәрәфи Хәсәнов иҗаты, “Беренче күк күкрәү” хикәясе. | 19.05 |
| 68 | Ямьле сабантуйлары. | Камил Каримов иҗаты, “Тимергали бабай хикәяте”әсәре. | 24.05 |
| 69 | “Ялкын” журналына сәяхәт. | “Ялкын” журналы. «Табигатьнең дә җаны, рухы бар» бүлеген гомумиләштереп кабатлау. | 26.05 |
| 70 | Күңелемә уелып калган әсәрләр (Әдәбият дигән олы дингез). | Ел буена үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау. | 31.05 |

Пронумеровано,прошнуровано

13(тринадцать)

Учитель татарского языка и литературы

Чибинова Лилия Раисовна

общеобразовательная школа №2 с углубленным изучением отдельных предметов»
ИНН 1605001185